ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

# “Татарстан Республикасында кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү турында” Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2016 елның 3 ноябрендә
кабул ителде

**1 статья**

“Татарстан Республикасында кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү турында” 2010 елның 21 гыйнварындагы 7-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2010, № 1 – 2; 2011, № 10 (I өлеш), 12 (I өлеш); 2014, № 1 – 2, № 5; 2015, № 10 (I өлеш); 2016, № 3) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 4 статьяга түбәндәге эчтәлекле 6 өлеш өстәргә:

“6. Вәкаләтле орган “Кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү федераль корпорациясе” акционер җәмгыятенә федераль законнарда билгеләнгән тәртиптә һәм срокларда Федераль законның $15^1$ статьясындагы 2 өлешендә һәм 16 статьясындагы 6 өлешендә каралган белешмәләрне җибәрә.”;

2) 6 статьяда:

а) 1 өлештә “Вәкаләтле орган ярдәм алучы кече һәм урта эшкуарлык субъектлары реестрын (алга таба – реестр)” сүзләрен “Вәкаләтле орган, җирле үзидарә органнары, Татарстан Республикасында кече һәм урта эшкуарлык субъектларына ярдәм итү инфраструктурасын булдыручы оешмалар ярдәм алучы кече һәм урта эшкуарлык субъектлары реестрларын (алга таба – реестрлар)” сүзләренә алмаштырырга;

б) 2 өлешнең 1 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“1) ярдәм иткән органның, оешманың исемнәре;”;

в) 3 өлештә “Кече һәм урта эшкуарлык субъектларына ярдәм итүче вәкаләтле орган кече һәм урта эшкуарлыкның тиешле субъектларына карата реестрга язмаларны” сүзләрен “Кече һәм урта эшкуарлык субъектларына ярдәм итүче Татарстан Республикасында кече һәм урта эшкуарлык субъектларына ярдәм итү инфраструктурасын булдыручы оешмалар, кече һәм урта эшкуарлык субъектларына ярдәм итүче вәкаләтле орган, җирле үзидарә органнары кече һәм урта

эшкуарлыкның тиешле субъектларына карата реестрга язмаларны" сүзләренә алмаштырырга;

3) 8 статьяда:

а) 1 өлештә "(эшкуарлыкны финанслаучы микрофинанс оешмаларын)" сүзләрен "(алга таба – эшкуарлыкны финанслаучы микрофинанс оешмалары), технопарклар (технологик парклар), технополислар, фәнни парклар, сәнәгать парклары, индустриаль парклар, агросәнәгать парклары белән идарә итүче оешмаларны, социаль өлкә инновацияләре үзәкләрен, сертификацияләү, стандартлаштыру һәм сынау үзәкләрен, халык сәнгать һөнәрләренә ярдәм итү үзәкләрен, авыл һәм экология туризмын үстерү үзәкләрен, кече һәм урта эшкуарлык субъектларына хезмәт күрсәтүче дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәкләрен" сүзләренә алмаштырырга;

б) 2 өлештә "Кече һәм урта эшкуарлык субъектларына" сүзләре алдыннан "Әгәр Федераль законда башкасы билгеләнмәгән булса," сүзләрен өстәргә;

4) 13 статьяга түбәндәге эчтәлекле $4^1$ өлеш өстәргә:

"$4^1$. Әлеге статьяның 4 өлешендәге 1 пунктында күрсәтелгән исемлекләргә кертелгән мөлкәткә карата шартнамәләр буенча аренда түләвенең ташламалы ставкасы күләме Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан билгеләнә.".

**2 статья**

1. Әлеге Закон, "Россия Федерациясендә кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү турында" 2007 елның 24 июлендәге 209-ФЗ номерлы Федераль законның $15^1$ статьясындагы 2 өлешендә каралган белешмәләр өлешендә әлеге Законның 1 статьясындагы 1 пунктыннан тыш, рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

2. Әлеге Законның 1 статьясындагы 1 пункты "Россия Федерациясендә кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү турында" 2007 елның 24 июлендәге 209-ФЗ номерлы Федераль законның $15^1$ статьясындагы 2 өлешендә каралган белешмәләр өлешендә 2017 елның 1 июленнән үз көченә керә.

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ АППАРАТЫ
ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ
АППАРАТ ПРЕЗИДЕНТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

Татарстан Республикасы
Президенты Р.Н. Миңнеханов

Казан,Кремль
2016 елның 19 ноябре
№ 88-ТРЗ